ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

«24» сентябрь, 2019 ел № 8/5

2019 елның 1 яртыеллыгына Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе М.А. Ионычевның «2019 елның 1 яртыеллыгына Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 5663,96 мең сум, чыгымнар буенча 4690,6 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
- 2019 елның 1 яртыеллыгы өчен Бәтке авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендәге мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Бәтке авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе М.А. Ионычев